| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» март 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 227

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» («Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасын уздыру кагыйдәләре», «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасын уздыру методикасы» белән бергә) 96 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2015 елның 21 августындагы 290 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

16 пунктта «яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында һәм информацион-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Р.Г.Айзатулловага йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин